


«Жинv паровозы»нын кочле гудогы ретросоставнын килvе турында хәбәр итте: ул Боек Ватан сугышы елларында совет халкынын батырлыгы турындагы хәтерне саклау символы булып хезмәт итә. Рузаевлылар һәм шәһәр кунакларынын тарихка кагылу, анын масштабын тою момкинлеге бар иде. Поезд башында - 1945 елнын жинv мае стилистикасында бәйрәмчә бизәлгән, хәрби еллар формасындагы Локомотив бригадасы идарәсендәге гамәлдәге «Лебедянка» паровозы.

Поезд экспозициясенә раритет техника белән



11 ачык платформа керә. Ретросоставта катнашучылар, Боек Ватан сугышы чоры формасын киеп, атмосфераны тулыландырдылар, тарихны кvзгә кvренеп торган иттеләр. Теләге булган һәркем алар белән техника фонында рәхәтләнеп фотога тоште.

Мордовия Республикасынын яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты рәисе Анастасия Гришнева ассызыклаганча, бу проект үткәнгә хөрмәт һәм үз иле өчен горурлык тәрбияли.



Рузаевка районы житәкчесе Александр Юткин билгеләп үткәнчә, «Жинү паровозы» - тимер юлчыларга - тылда жинүне яулаучыларга хөрмәт.

Үзенен чыгышында Куйбышев тимер юлынын баш инженеры урынбасары Ринат Хафизов сугыш елларында тимер юлчыларнын батырлыгы турында искә төшерде. Бомбалар астында алар заводларны тылга эвакуацияләгәннәр, яралыларны ташыганнар, солдатларны һәм сугыш кирәк-яракларын алгы сызыкка китергәннәр, диде.



Ретросостав шул хәрби эшелоннар белән бер рәттә тора - чор турындагы тере хәтер кебек ул.

Чыгышлардан сон оештырылган концерт программасында Самара һәм Рузаевка артистлары катнашты.

Ике сәгатьтән сон «Жинү паровозы» маршрут буенча хәрәкәтен дәвам итте.

Фото: Рузаевка муниципаль районы администрациясенен